13



# ЮРИЙ ТРУТНЕВ: ЭШЕ БАРНЫҢ СҮЗЕ БАР

—КӨЧЛЕ ШӘХЕС
—ЭКОНОМИСТ ҺӘМ СӘЯСӘТЧЕ
—ЭШ КЕШЕСЕ

## ТОРМЫШ ЮЛЫ.

Өлкәбезнең үзәге — Пермь шәһәре үз тарихын бик матур исемле Разгуляй районыннан алганын Пермь олкәсе халкы ишетеп-укып белә торгандыр. Менә шушы электән-электән эшче халык яшәгән урамнарның берсендә, 1956 ел язның беренче көнендә, Трутневлар гайләсендә Юра дөньяга килде.

Әти-әнисе нефтьчеләр, коне-төне эш артыннан йөргәч, малай тәрбияләү күбрәге әби-бабай җилкәсенә төште.

Юраның бала һәм үсмер чагы, шул вакытта үскән башка балаларныкы шикелле, пионер һәм комсомол оешмаларында үтте.

Укырга иренмәве, бигрәк тә математика, химия һәм тарих фәннәреннән тырышып укуы малайның алдына ярады.

Мәктәпие тәмамлагач, әти-әнисе юлын кабатлап, Пермь политехник институтына укырга керде.

Институтны яхшы тәмамлавы уңае белән, институт галимләре, зирәк укучыны ерак җибәрергә теләми, кафедрада эш тәкъдим иттеләр.

Юра укыту эше белән генә чикләнмәде, институт яшьләр оешмасында иҗтимагый эшләр алып барды.

Тиздән бу дәртле егетнең оештыру сәләтен күрен, олкә комсомол оешмасын җитәкләргә чакырдылар.

## РОМАНТИК.

«Таудан гүзәл тау гына», – ди халык әйтеме. Күп еллар элек көчкенә Юрага Егошиха елгасының текә яры да биек тау булып күренә иде. Юра үсте, аның белән бергә ул менгән таулар да биегәйде: Урал тавы, Коль ярымутравы, Памир...

Шәхесен чыныктырыр өчен елдан ел үзен авырлыклар белән сынады. Бу сынаулар тик кенә утмәде: Юра тормышның, дусларның кадерен бирергә ойрәнде. Бу егет авыр минутта, бәлә-казада баш бора торганнардан түгел, ышандыклы кеше. Моны Юраны якын белгән һәркем әйтә ала.

## КӨЧЛЕ — ДИМӘК, МӘРХӘМӘТЛЕ.

Сунарчы-аучы сәләте — рухи кочлеләр гамәле. Тормыш сынауларында богәлә торган кешедән аучы чыкмый.

Юрийғың күп мәртәбә аюга каршы чыгуыда тормыш сынауларының берседер. Бу имтиханны да уңыш белән тоткач, ғеше хайваннан кочле, ә кочледә мәрхәмәт күбрәк булырга тиеш дигән фикергә килде.

## БАШТА АКЫЛ, КУЛДА КӨЧ.

Юрий Трутнев җитәкче кешенең көчсез һәм куркак булуы мөмкин түгел, дип исәпли. Бәлкем, җитәкче үз якыннары өчен генә түгел, аңа ышаныч баглаган халык өчен дә җаваплы. Шәһәр башлыгы булганнан бирле, буш вакыты бик нык азайса да, спорт белән шөгелләнүен ташламады: көрәш һәм штангага вакыт таба, шуңа күрә җан сакчысы тотуны да кирәк дип тапмый.

## ОСТА КУЛЫНДА ЭШ ЯНА.

Трутневның сәләтләре һәм аның кызыл нефтьче дипломы белән, кай берәү инде күптән илебезнең нефть байлыкларын сатырга керешер иде. Бөтен халык байлыгын таркатуны Юрий дөрес дип исәпләми, шуңа күрә өлкә үзәгендә берничә ел элек үзенең финанс һәм сәнәгать группасы — «Экс» ны ачты. Беренче елларда «Экс» та 2-3 кеше генә эшләсә, бугенге көндә «Экс» Пермь шәһәренең иң зур эш урыннарының берсе, ә Пермь белем һәм сәнгать оешмалары өчен «Экс» — беренче ярдәм кулы.

Юрий Трутнев «Экс» башлыгы булудан башка, берничә ел шәһәр Думасы депутаты, соңрак өлкә Законнар Язу Җыелышы депутаты булып та үз округ халкына күп ярдәм күрсәтте. Депутат буларак сайлайчыларын ихтирам итә белгәч, 1996 елда миллионлы шәһәр халкы бер итеп Юрий Трутневны шәһәр башлыгы итеп сайлап куйды.

Инде 4 ел өлкә үзәгендә эш хакы һәм пенсияләр тоткарланмый, пенсия алучылар шәһәр бюджетыннан өстәмә акча алып торалар, шәһәрдә «Ветеран» магазиннары ачылды.

Өлкәдән килгәннәр дә күрә торгандыр, Пермь шәһәре соңгы елларда бик үзгәрде: юллары тигезләнә, йортлары яңара, кешеләре елдан ел ешрак елмая.

## БУРЫЧ.

Юрий Трутнев әйткән сүзендә тора торган кешеләрнең берсе.

Күптән түгел Өлкә башлыгы үз исемен сайлаудан алып, ә аңа ышаныч баглаган кешеләргә: «шушы сайлауларда Юрий Трутневка тавышыгызны бирсәгез җиңел күңел белән ялга китәр идем», — дип халыкка мөрәҗәгать итте. Трутнев лаеклы өлкән кешенең соравына каршы килмәде, өлкә башлыгы сайлавына барырга вагдә бирде.

Вагдә үтәүне сорый.

Өлкәнең вак шәһәр-авылларында яшәгән халык Пермь кешеләреннән начар яшәргә тиеш түгел. Яңа вакыт яңа җитәкчеләр сорый.

Заказчик: кандидат на должность Губернатора Пермской области Трутнев Ю.П.
Изготовитель: ЗАО «Диалог-Пермь», ул. Горького, 76. Тираж 1500 экз. 30.10.2000. Оплачено с избирательного фонда кандидата на должность Губернатора Пермской области Трутнева Ю.П.